**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ**
**КАРАРЫ**

**№ 1** **07.12.2019ел**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге составына керүче Илбәк авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2019 елның 07 декабрендә түбәндәге сорау буенча узган, гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде:

«Сез Илбәк авыл җирлеге Илбәк торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә, 2 төркем инвалидларыннан, 80 яшьтән өлкән пенсионерлардан, күп балалы гаиләләрдән бер тапкыр түләтүне 250 сумга киметеп, 2020 елда үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Илбәк авылында бәйрәм чараларын (“Сабантуй”, Яңа ел” бәйрәмнәрен) үткәрү өчен хезмәтләр күрсәтү, бүләкләр һәм сувенир продукциясе сатып алу, бәйрәм исеме язылган баннерлар ясату;
- Илбәк авылындагы урамнарны яктырту өчен энергияне саклый торган лампалар, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урам яктырту һәм ремонт эшләре буенча хезмәтләр өчен түләү;
- Илбәк авылы мәдәният йорты өчен музыкаль аппаратура сатып алу;
- Илбәк авылындагы юлларны кардан чистарту;
- Илбәк авылы зираты өчен төзелеш материаллары, хуҗалык товарлары, инвентарь һәм инструментлар сатып алу.

ӘЙЕ ЮК».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда, сайлау хокукына ия булучы катнашучылар исемлегендә 167 кеше теркәлгән, җыенда тавыш бирүдә катнашучылар саны - 118 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

халык җыенында катнашучы 107 кеше «Әйе» позициясе өчен тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 11 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены **карар чыгарды:**

1. Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге составына керүче Илбәк авылыдна узган халык җыенын узган, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге сорау буенча карарны кабул итәргә: «Сез Илбәк авыл җирлеге Илбәк торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ

булган, 1төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә, 2 төркем инвалидларыннан, 80 яшьтән өлкән пенсионерлардан, күп балалы гаиләләрдән бер тапкыр түләтүне 250 сумга киметеп, 2020 елда үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Илбәк авылында бәйрәм чараларын ("Сабантуй", Яңа ел" бәйрәмнәрен) үткәрү өчен хезмәтләр күрсәтү, бүләкләр һәм сувенир продукциясе сатып алу, бәйрәм исеме язылган баннерлар ясату;
- Илбәк авылындагы урамнарны яктырту өчен энергияне саклый торган лампалар, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урам яктырту һәм ремонт эшләре буенча хезмәтләр өчен түләү;
- Илбәк авылы мәдәният йорты өчен музыкаль аппаратура сатып алу;
- Илбәк авылындагы юлларны кардан чистарту;
- Илбәк авылы зираты өчен төзелеш материаллары, хуҗалык товарлары, инвентарь һәм инструментлар сатып алу.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru һәм Илбәк авылы, Ә.Вәлиев урамы, 10а; Илбәк авылы, Ә.Вәлиев урамы, 50 йорт адреслары буенча урнашкан мәгълүмат стендында урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Илбәк авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Илбәк авыл җирлеге Башлыгы Л.Р.Әсәдуллина